**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәр муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча шәһәре,Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-15-25, 3-16-25**

**Республика Татарстан**
**Муниципальное образование город Арск**
**Арского муниципального района**
**Совет города Арск**
**422000, г. Арск, Площадь Советская , 27**
**тел. 3-15-25, 3-16-25**

**Арча шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

**« 07 » июнь 2022 ел** **№ 69**

**« Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәне раслау турында» Арча шәһәр Советының 2016 елның 18 апрелендәге 31 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022елның 01 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указы нигезендә Арча шәһәр Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәне раслау турында» Арча шәһәр Советының 2016 елның 18 апрелендәге 31 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 абзацның 1 пунктында «акцияләрне» сүзен төшереп калдырырга;

1.2. 8 пунктның 3 пунктчасында «акцияләрне» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасарына йөкләргә.

«Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе И.Г.Нуриев